РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 7 мае

Кукмара шәһәре

№ 283

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм чаралары турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 19 мартындагы 670-р номерлы боерыгын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 820-р номерлы һәм 821-р номерлы күрсәтмәләрен үтәү йөзеннән һәм яңа коронавирус инфекциясе (COVID-19) таралу фонында эшлекле һәм куллану активлыгы кимү чорында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү максатларында Кукмара муниципаль район Советы **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен аренда түләүләрен түләүне кичектереп тору, аренда түләүләреннән азат итү һәм реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен түләүләрне кичектереп торуны бирүнең кушып бирелгән Тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.
2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә гавами мөлкәт арендаторлары – кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының Бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары Палатага өстәмә килешү төзү турында гариза белән мөрәҗәгать итү урынына, Тәртип нигезендә Палатага 2020 елда каралган аренда түләвен кичектереп торуны күздә тоткан өстәмә килешү төзү турында һәм (яисә) «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 1 апрелендәге 98-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясында һәм әлеге Федераль законның күрсәтелгән статьясы нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актында каралган тәртиптә һәм

шартларда аренда түләве күләмен үзгәртү хакында өстәмә килешү төзү турында гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы, дип билгеләргә.

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә гавами мөлкәт» төшенчәсе әлеге пунктның беренче абзацында Тәртипнең 2 пунктындагы 2.3 пунктчасында китерелгән мәгънәдә кулланыла.

3. Кукмара муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына (алга таба – Палата) тәэмин итәргә:

- «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында әлеге карар үз көченә кергән көннән 7 эш көне эчендә арендаторлар – кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының Бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары һәм реклама конструкцияләре хуҗалары – кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының Бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары игътибарына Тәртип нигезендә өстәмә килешүләр төзү мөмкинлеге турында мәгълүмат урнаштыру;

- Тәртипне саклау.

4. Әлеге Карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасын Хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Район Башлыгы Димитриев С. Д.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль район Советының 2020 елның 7 маендагы 283 номерлы карарына кушымта

# Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен аренда түләүләрен түләүне кичектереп тору, аренда түләүләреннән азат итү һәм реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен түләүләрне кичектереп торуны бирү Тәртибе

1. Әлеге Тәртип (алга таба – Тәртип) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 19 мартындагы 670-р номерлы Боерыгын (алга таба – 670-р номерлы Боерык), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 820-р номерлы һәм 821-р номерлы Боерыкларын үтәү йөзеннән һәм яңа коронавирус инфекциясе (COVID-19) таралу фонында эшлекле һәм куллану активлыгы кимү чорында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү максатларында эшләнде.

2. Тәртиптә түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

2.1. 98-ФЗ номерлы Федераль закон − «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 1 апрелендәге 98-ФЗ номерлы Федераль закон;

2.2. Палата – Кукмара муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы;

2.3. Гавами мөлкәт – Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль казнасын тәшкил итә торган муниципаль милке (шул исәптән Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль милкендә булган җир кишәрлекләре), ягъни муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә беркетелмәгән мөлкәт; дәүләт милке чикләнмәгән һәм аларны бирү Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә законнар белән кертелгән җир кишәрлекләре (Тәртип нигезендә аренда түләүләрен кичектереп тору, аренда түләүләрен түләүдән азат итү, реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен түләүләрне кичектереп тору турында мөрәҗәгатьләрне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Палата тарафыннан карар кабул ителгән көнгә);

2.4. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты − кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының Бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты;

2.5. Аренда түләвен кичектереп тору турында килешү – 98-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы нигезендә Палата һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты арасында төзелгән 2020 елда каралган аренда түләвен кичектереп торуны күздә тота торган өстәмә килешү;

2.6. Аренда түләве күләмен үзгәртү турында килешү – 98−ФЗ номерлы

Федераль законның 19 статьясы нигезендә Палата һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты арасында төзелгән аренда түләве күләмен үзгәртү турында өстәмә килешү;

2.7. Өстәмә килешү – Палата һәм арендатор-кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты арасында төзелә торган гавами мөлкәтне арендалау шартнамәсенә кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты тәкъдим иткән вакытка аренда түләүләрен түләүне кичектереп тору турында өстәмә килешү, әмма 2021 елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча (аренда түләвен кичектереп тору һәм аренда түләве күләмен үзгәртү турындагы килешүдән тыш); Палата һәм реклама конструкциясе хуҗасы-кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты арасында төзелә торган реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү шартнамәсенә реклама конструкциясе хуҗасы тәкъдим иткән вакытка өстәмә килешү, әмма 2021 елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча.

3. Гавами мөлкәт арендаторы булган кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты Палатага 2020 елның апрель-июнь айларында гавами мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен түләүне кичектереп тору турында гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы, әмма 2021 елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча.

Гавами мөлкәт арендаторы булып торучы һәм 670-р номерлы боерыкның 1 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы (алга таба – Эшчәнлек төрләре) кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты Палатага 2020 елның апрель-июнь айлары өчен гавами мөлкәт шартнамәләре буенча аренда түләүләрен түләүдән азат итү турында гариза белән, гаризага күрсәтелгән эшчәнлек төрен (күрсәтелгән эшчәнлек төрләрен) гамәлгә ашыру өчен тиешле гавами мөлкәттән файдалануны раслый торган документлар кушып мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

4. 2020 елның апрель – июнь айлары өчен гавами мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен түләүне кичектереп тору түбәндәге шартлар тулаем булганда бирелә:

- Палата һәм гавами мөлкәт арендаторы арасында төзелгән аренда түләвен кичектереп тору турында килешү һәм аренда түләве күләмен үзгәртү турында килешү юк;

- 2020 елда Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек режимын кертү датасына кадәр булган чор өчен аренда түләүләрен түләү буенча гавами мөлкәт арендаторының үтәлмәгән бурычы юк.

5. 2020 елның апрель – июнь айлары өчен гавами мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен түләүдән азат итү түбәндәге шартлар тулаем булганда гамәлгә ашырыла:

- гавами мөлкәт арендаторы Эшчәнлек төрләрен башкара;

- гавами мөлкәтне арендалау шартнамәсендә, эшчәнлек төрен (эшчәнлек төрләрен) гамәлгә ашыру өчен, аннан файдалану максатларында, гавами мөлкәтне арендага бирү каралган;

- Эшчәнлек төрен (Эшчәнлек төрләрен) гамәлгә ашыру өчен тиешле мөлкәтне куллануны раслаучы документлар бар;

- Палата һәм гавами мөлкәт арендаторы арасында төзелгән аренда түләвен

кичектереп тору турында килешү һәм аренда түләве күләмен үзгәртү турында килешү юк;

- 2020 елда Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек режимын кертү датасына кадәр булган чор өчен аренда түләүләрен түләү буенча гавами мөлкәт арендаторының үтәлмәгән бурычы юк.

6. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә реклама конструкциясе хуҗасы булган һәм Палата белән реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә килешү төзегән кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты палатага әлеге килешү нигезендә, 2020 елның апрель – июнь айларында реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен исәпләнгән түләүләрне кичектереп тору турында, аларга кичектерүнең тәкъдим ителгән вакытын күрсәтеп, әмма 2021 елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча, гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән түләүләрне түләүне кичектерү әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектының 2020 елда Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек режимын кертү датасына кадәр Палата белән төзелгән шартнамә нигезендә исәпләнгән реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен түләүләр түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаса бирелә.

7. Тәртипнең 3 һәм 6 пунктларында каралган гаризаларда түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

- гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булган очракта), гариза бирүченең яшәү урыны һәм гариза бирүченең шәхесен таныклаучы документ реквизитлары, шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрында шәхси эшмәкәрне дәүләт теркәвенә алу турындагы язманың дәүләт номеры (шәхси эшмәкәр өчен);

- юридик затның исеме һәм урнашу урыны, юридик затларның бердәм дәүләт реестрында юридик затның дәүләт теркәвенә алу турындагы язманың дәүләт теркәү номеры (юридик зат өчен);

- салым түләүченең идентификация номеры;

- гариза бирүче белән элемтә өчен почта адресы һәм (яки) электрон почта адресы;

- реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә түләүләр исәпләнгән һәм гариза бирүче аларга карата түләүне кичектереп торуны (түләүдән азат итү) сорый торган аренда түләүләре исәпләнгән айлар (чор); шул ук вакытта гаризада күрсәтелгән айлар (гаризада күрсәтелгән чор) 2020 елның апреленнән алып июненә кадәрге чор чикләрендә булырга тиеш;

- аренда түләүләрен түләүне кичектерүнең тәкъдим ителә торган вакыты, реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен түләүләрне кичектереп тору вакыты (аренда түләүләрен кичектереп тору һәм реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен исәпләнгән түләүләрне кичектереп тору турында гаризаларда), ләкин 2021 елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча.

Тәртипнең 3 пунктында каралган гаризаларда, моннан тыш, түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

- Кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты аренда түләвен кичектереп тору турында килешү төзү, аренда түләве күләмен үзгәртү турында килешү төзү мөмкинлеген регламентлый торган 98-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре белән һәм күрсәтелгән Федераль законның 19 статьясындагы 1 өлешен үтәү йөзеннән кабул ителгән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый акты белән танышты;

- Кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты, аның белән өстәмә килешү төзегән очракта, 98-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы нигезендә өстәмә килешүдә каралган ярдәм чараларын алу хокукын югалта.

8. Гариза һәм аңа кушып бирелә торган документлар (булган очракта) Палатага түбәндәге ысулларның берсе белән кәгазьдә тапшырыла:

- шәхсән яисә закон нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә гариза бирүче исеменнән эш итүче зат тарафыннан (шәхси эшмәкәрләр өчен);

- юридик зат исеменнән ышаныч кәгазеннән башка эш итәргә хокуклы зат яисә гариза бирүче исеменнән законнар нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче зат (юридик затлар өчен);

- заказлы почта белән.

Гариза бирүче 2020 елда Татарстан Республикасы территориясендә кертелгән югары әзерлек режимы (гадәттән тыш хәл режимы) чыккан көнгә кадәр гариза һәм аңа кушып бирелә торган документларны (алар булган очракта) Ilyas.Z@tatar.ru электрон почта адресына җибәрергә хокуклы: Бу очракта гариза һәм документлар сканерлау чаралары ярдәмендә булдырыла торган электрон образ рәвешендә җибәрелә. Сканерлау 1:1 масштабында, документның барлык реквизитларын һәм аутентик билгеләрен саклауны тәэмин итә торган кара-ак яки соры төстә, аерым алганда: затның график имзасы, мөһер һәм бланкның почмак штампы (булганда); төсне тулы тапшыру режимында сканерлау документта төсле график сурәтләр яисә төсле текст булганда гамәлгә ашырыла. Документның электрон формадагы файлы PDF форматында яки JPEG форматында (киңәйтү .jpeg яки .jpg).булырга тиеш. Бу очракта, 2020 елда Татарстан Республикасы территориясендә кертелгән югары әзерлек режимы (гадәттән тыш хәл режимы) тәмамланган көннән соң ун көнлек срок тәмамланганчы, Палатага гариза һәм аңа кушып бирелә торган документлар (алар булган очракта) кәгазьдә тапшырылырга тиеш.

Арендатор-кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан, реклама конструкцияләре хуҗаларыннан, реклама конструкцияләре хуҗалары-кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан гаризаның тәкъдим ителгән формасы Тәртипкә кушымтада бирелгән.

9. Палата аренда түләүләрен кичектереп тору, аренда түләүләрен түләүдән азат итү, реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен исәпләнгән түләүне кичектереп тору турында гариза кергән көннән җиде эш көне эчендә:

- гариза бирүчегә гаризаны һәм аңа кушып бирелгән документларны (алар булган очракта) түбәндәге очракларның берсе генә булса да кире кайтара: а) гариза Тәртипнең 7 нче пункты таләпләренә туры килми; б) электрон формадагы гариза һәм аңа кушып бирелгән документлар (алар булган очракта) Тәртипнең 8

пунктындагы бишенче абзацы таләпләренә туры килми; в) аренда түләүләрен түләүдән азат итү турындагы гаризага Тәртипнең 3 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән документлар теркәлмәгән; г) кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты белән Палата арасында гавами мөлкәтне арендалау шартнамәсе юк (аренда түләүләрен кичектереп тору турында гариза биргәндә, аренда түләүләреннән азат итү турында гариза кергәндә); д) кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты белән Палата арасында реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамә юк (төзелмәгән) (реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен исәпләнгән түләүне кичектереп тору турында гариза биргәндә); е) гариза 2020 елның 1 октябреннән соң бирелгән;

- Тәртиптә каралган нигезләр булмаганда, өстәмә килешү төзүдән баш тарту турында язма карар кабул итә һәм әлеге карарны гариза бирүчегә җибәрә.

- өстәмә килешү проектын әзерләүне гамәлгә ашыра һәм гариза бирүчегә кул кую өчен өстәмә килешү проектын җибәрә.

Гаризада почта адресы һәм (яки) гариза бирүче белән элемтә өчен электрон почта адресы күрсәтелмәгән очракта яисә күрсәтелгән адреслар аңлап укырлык түгел икән, Палата тарафыннан мондый гариза кергән көннән җиде эш көне эчендә, гаризада башка адреслар булмаган, һәм Палатаның гариза бирүче адресын юридик затларның бердәм дәүләт реестрында/шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрында булган мәгълүматларга мөрәҗәгать итү юлы белән билгеләү мөмкинлеге булмаган очракта, гаризаны карамыйча калдыру турында язма карар кабул ителә.

10. Гавами мөлкәтне арендалау шартнамәсенә өстәмә килешү түбәндәгеләр турында шартларны үз эченә алырга тиеш:

- әлеге килешү якларының хокуклары һәм бурычлары түбәндәге очракларның берсе генә булса да туктатылган дип санала: а) Палата һәм арендатор-кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты арасында аренда түләвен кичектереп тору турында килешү һәм (яки) аренда түләве күләмен үзгәртү турында килешү төзегәндә; б) Палатага кәгазьдә гариза һәм аңа кушып бирелгән документлар (алар булган очракта) Тәртипнең 8 пунктындагы бишенче абзацында каралган срокта кермәгән булса, в) кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты кул куйган әлеге килешү 2020 елда Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә кертелгән югары әзерлек режимы (гадәттән тыш хәл режимы) чыккан көннән алып 30 көн эчендә Палатага кермәгәндә;

- әлеге килешү нигезендә кичектереп тору (түләүдән азат итү) бирелгән аренда түләүләре законнарда һәм аренда шартнамәләрендә каралган тәртиптә (кичектерү бирүне (түләүдән азат итүне) исәпкә алмыйча) кертелергә (яңадан торгызылырга) тиеш), (әгәр аренда түләвен кичектереп тору (түләүдән азат итү) турында килешүдә һәм (яисә) аренда түләве күләмен үзгәртү турында килешүдә башкасы каралмаган булса (әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән очракларның берсе генә булган очракта да);

- гавами мөлкәт арендаторы, гавами мөлкәтне арендалау шартнамәсен вакытыннан алда өзгән очракта, кичектерелгән түләүләрне вакытыннан алда кертергә тиеш.

11. Реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү

шартнамәсенә өстәмә килешү түбәндәгеләр турында шартларны үз эченә алырга тиеш:

- әлеге килешү якларының хокуклары һәм бурычлары түбәндәге очракларның берсе генә булса да, туктатылган дип санала: а) Палатага кәгазьдә гариза һәм аңа кушып бирелгән документлар (алар булган очракта) Тәртипнең 8 пунктындагы бишенче абзацында каралган срокта кермәгән булса, в) кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты кул куйган әлеге килешү 2020 елда Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә кертелгән югары әзерлек режимы (гадәттән тыш хәл режимы) чыккан көннән алып 30 көн эчендә Палатага кермәгәндә;

- әлеге килешү нигезендә кичектереп тору бирелгән түләүләр законнарда һәм реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләү шартнамәсендә каралган тәртиптә (кичектерү бирүне исәпкә алмыйча) (әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән очракларның берсе генә булган очракта да) кертелергә (торгызылырга) тиеш;

- реклама конструкциясе хуҗасы, реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләү шартнамәсен вакытыннан алда өзгән очракта, кичектерелгән түләүләрне вакытыннан алда кертергә тиеш.

12. Өстәмә килешүдә түбәндәге шартлар булырга тиеш түгел:

- гавами мөлкәт арендаторының аренда түләүләрен кертү тәртибен һәм срокларын (шул исәптән, әгәр мондый чаралар аренда шартнамәсендә каралган очракларда) үтәмәүгә бәйле рәвештә, реклама конструкциясе хуҗасы тарафыннан реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә түләүләрне кертү тәртибен һәм срокларын үтәмәүгә бәйле рәвештә (шул исәптән мондый чаралар реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамә белән каралган очракларда да), кичектереп тору (түләүдән азат итү) бирелгән аренда түләүләре, реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен кичектереп тору бирелгән түләүләр өлешендә чит акчалардан файдаланган өчен штрафлар, процентлар яки башка җаваплылык чаралары турында;

- аренда түләүләрен түләүне кичектереп тору, аренда түләүләрен түләүдән азат итү белән бәйле рәвештә гавами мөлкәт арендаторы тарафыннан һәм реклама конструкциясе хуҗасы тарафыннан реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен исәпләнгән түләүләрне түләүне кичектереп тору белән бәйле түләнергә тиешле өстәмә түләүләрне кертү турында.

13. Өстәмә килешү, аны төзү датасына бәйсез рәвештә, әлеге айлар (чор) 2020 елның апреленнән алып июнь аен кертеп булган чор чикләрендә булган очракта, кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты гаризасында күрсәтелгән айлар (чор) өчен кичектереп тору (түләүдән азат итү) бирелгән аренда түләүләрен, кичектереп тору бирелгән реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен түләүләрне үз эченә алырга тиеш.

14. Аренда түләүләрен түләүне кичектереп тору, аренда түләүләрен түләүдән азат итү һәм реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен исәпләнгән түләүләрне түләүдән кичектерү Палата тарафыннан өстәмә килешү проектына кул куйганнан соң бирелә.

Тәртипнең 10 пунктында каралган нигезләр булганда, өстәмә килешү

нигезендә кичектереп тору (түләүдән азат итү) законда һәм аренда шартнамәләрендә каралган тәртиптә (кичектерү бирүне (түләүдән азат итүне) исәпкә алмыйча) кертелергә (яңадан торгызылырга) тиеш.

Тәртипнең 11 пунктында каралган нигезләр булганда, өстәмә килешү нигезендә кичектереп тору бирелгән реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен түләүләр законнарда һәм реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәдә каралган тәртиптә (кичектерү бирүне исәпкә алмыйча) кертелергә (яңадан торгызылырга) тиеш.

Район Башлыгы урынбасары Р. А. Кәримуллина